**«Халыкара туган тел көне» - 2021.**

21 нче февральдә «Халыкара туган тел» көне билгеләп үтелә. Шул уңайдан бакчабызда төрле чаралар уздырылды: зурлар төркеме балалары белән «Әбием сандыгы» исемле чара оештырылды. Әлеге чарада балалар татар халык йолалары, милли киемнәр, чигү үрнәкләре белән таныштылар. Мәктәпкә әзерлек төркеме балалары белән «Нәрсә ул фольклор?» исемле бәйге оештырылды. Әлеге бәйгедә балалар татар халкының милли мәдәниятына, сәнгатенә, йолаларына багышланган белемнәрен ныгыттылар.









